«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлегенең Тутай авылында халык җыены нәтиҗәләре һәм 2025 елда үзара салым кертү турында» 2024 елның 22 ноябрендәге 2 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлегенең Тутай авылында гражданнар җыенының карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә

«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Тутай авыл җирлегенең Тутай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш; балачактан инвалидлар; инвалид-коляскалылар; Бөек Ватан сугышында катнашучылар; Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары; күп балалы гаиләләр; махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, хәрбиләр һәм аларның гаилә әгъзалары, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның югарыда күрсәтелгән категорияләренең гаилә әгъзалары, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны үз теләге белән үтәүче гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары арасыннан) 500 (биш йөз) сум күләмендә 2025 елда үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча:

- Тутай авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (тракторны тоту, трактор өчен җиһазлар сатып алу) белән килешәсезме?» дигән мәсьәлә буенча 2024 елның 22 ноябрендә Тутай авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 122 кеше кертелгән, тавыш бирүдә кеше катнашкан гражданнар саны 73 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда 73 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлегенең Тутай авылында халык җыенын узган дип, халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Тутай авыл җирлегенең Тутай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш; балачактан инвалидлар; инвалид-коляскалылар; Бөек Ватан сугышында катнашучылар; Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары; күп балалы гаиләләр; махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, хәрбиләр һәм аларның гаилә әгъзалары, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның югарыда күрсәтелгән категорияләренең гаилә әгъзалары, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны үз теләге белән үтәүче гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары арасыннан) 500 (биш йөз) сум күләмендә 2025 елда үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча:

- Тутай авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (тракторны тоту, трактор өчен җиһазлар сатып алу)» дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Тутай авыл җирлегенең Тутай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган

яшәүчедән (көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш; балачактан инвалидлар; инвалид-коляскалылар; Бөек Ватан сугышында катнашучылар; Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары; күп балалы гаиләләр; махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, хәрбиләр һәм аларның гаилә әгъзалары, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның югарыда күрсәтелгән категорияләренең гаилә әгъзалары, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны үз теләге белән үтәүче гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары арасыннан) 500 (биш йөз) сум күләмендә 2025 елда үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча:

- Тутай авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (тракторны тоту, трактор өчен җиһазлар сатып алу) эшләрен башкарырга юнәлдерергә.

4.Әлеге карарны мәгълүмат стендлары аша халыкка белдерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Тутай авыл җирлеге Башлыгы Н.М.Насретдинова.